Республика Татарстан
Глава Верхне-Чершилинского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Югары Чыршылы авыл
жирлеге башлыгы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11. 2022г № 4

2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл жирлегенең Югары Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1. Югары Чыршылы авылы мәдәният йорты бинасы янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 18 ноябренә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш 2023 елда 700 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Югары Чыршылы авылында су үткәргечне алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Югары Чыршылы авылында өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) Югары Чыршылы авылында артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяу сатып алу, эшләр өчен түләү);

4) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар сатып алу;

5) МТЗ-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу;

6) Югары Чыршылы авылы зираты өчен чапкыч (триммер) сатып алу;

7) Югары Чыршылы авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

8) Югары Чыршылы авылында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны җыештыру һәм чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ «ЮК»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1031604001000
Совет Верхне-Чершилинского сельского поселения
Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы
ИНН 1636001964